Рузия Сафиуллина

# ТАТАР ТЕЛЕН БАШКАЧА ДА ӨЙРӘТЕРГӘ МӨМКИН

Хәзерге вакытта туган тел предметы уку планының мәҗбүри өлешендә урнашкан. Әлеге предмет кысаларында әти-әниләр, укучылар үзләре өйрәнергә теләгән телне (татар, рус, чуаш һ.б.) сайлап алалар.

2016 елда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында милли мәгариф бүлеге оештырылды. Яңа оештырылган бүлектә федераль белем бирү стандартларына да җавап бирерлек, тикшерүче органнар да сүз әйтә алмаслык, укучыларга, укытучыларга кулай-аңлаешлы татар теле-әдәбияты дәреслекләре әзерләнә башлады. Яңа әсбаплар – гади дәреслек кенә түгел. Бу – заманча мультимедияле укыту-методик комплектлары, һәм алар инде Татарстанның аерым мәктәпләрендә сынау уза. Дәреслекләр дизайн, комплектация ягыннан чит илдә чыгарылган китаплардан һич калышмый: җете рәсемле, матур һәм креатив.



Ким Миңнуллин

*Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры **Ким Миңнуллин**, институтның милли мәгариф бүлеге мөдире **Гөлназ Мөхәрләмова**, дәреслек авторлары **Мөслимә Шәкүрова, Лилия Гыйниятуллина** «Идел» журналы редакциясе вәкиленә яңа дәреслекләр һәм татар телен укыту перспективалары турында сөйләде.*





Фотолар – Г. Ибраһимов исемендәге ТӘһСИ архивыннан

**«ИДЕЛ»: Г. Ибраһимов исемендәге институт галимнәре яңа бүлек ачылганчы да татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен язганмы?**

**К.М.:** Безнең институт хезмәткәрләренең совет чорыннан ук мәктәп системасы белән бәйләнеше булган. Галимнәребез, КДУ һәм педуниверситет галимнәре белән берлектә, тел һәм әдәбият буенча дәреслекләр әзерләүгә катнашып килде. Соңгы елларда дәреслекләр язуда институт галимнәренең турыдан-туры катнашу ихтыяҗы туды. Милли мәгариф бүлеген төзү – заман таләбе иде.

Дәреслекләргә ихтыяҗ һәрвакыт булды, алар һәрдаим язылып, яңартылып торды. Вузларда эшләгән татар теле һәм әдәбияты укытучыларының күбесе дәреслек язуга җәлеп ителде. Милли мәгариф бүлеген оештырыр алдыннан, барлык дәреслекләрне алып, авторларның исемлеген төзи башлаган идек, тик очына чыга алмадык. Бу сандагы дәреслек язучы була аламы?



**Г.М.:** Шушы берничә елда бик күп эшләр башкарылды. Бүген бүлек хезмәткәрләре дәреслек төзү буенча аеруча актив эшлиләр. Турырак итеп әйткәндә, туган (татар) теленнән беренче сыйныфтан башлап дүртенче сыйныфка кадәр укыту-методик комплектлары әзер. Һәркайсы дәреслек буенча методик кулланма, программа, балаларга эш дәфтәре, электрон дәреслек, аудиодәреслек. Болар барысы да бер линия, комплект булып бара, бизәлеше дә бер үк стильдә башкарылган.

Шулай ук башлангыч сыйныфлар өчен әдәби уку дәреслеген төзи башладык. Быел әлеге уку предметы буенча укыту-методик комплектларын эшләп тапшырырбыз дип өметләнәбез.

Бүлек хезмәткәрләре ел саен татар теле һәм әдәбияты буенча республика һәм халыкара олимпиадаларны, «Ел укытучысы» һөнәри осталык конкурсларын оештыру һәм үткәрүдә катнаша. Гомумән, укучылар һәм укытучылар белемենә, осталыгына эксперт бәясе бирү таләп ителгән һәр җирдә безне жюри әгъзалары буларак та җәлеп итәләр. Моңа өстәп, фәнни юнәлешне дә алып барабыз: монографияләребез, фәнни мәкаләләребез басыла тора.

**«ИДЕЛ»: Заманча дәреслек, чит телләргә өйрәтү дәреслекләре мисалында, коммуникатив күнекмәләрне үстерә һәм, кагыйдә ятлатудан бигрәк, аралашуга корылган. Шәһәр балалары өчен кулайдыр ул, тик авылдагы татар балаларына кызыклы булырмы соң? Алар бит болай да көн саен татарча аралаша…**



**М.Ш.:** Сез шулай дип уйлыйсызмы? Хәзер татар балаларының күбесе авылларда да русча аралаша, сөйләшә башлады, чөнки мультфильмнар, компьютердагы, телефондагы уеннар – бөтенесе рус телендә. Мин үзем Саба районыннан, шул якка кайтып йөрим. Үзебезнең




*Татар теле дәреслекләре мәктәпләрдә сынау уза*






Дәреслек сәхифәләре

авылдагы туган-тумачаның балалары да русча сиптерә генә! Балалар бакчасыннан ук укыту-тәрбия эшләре татар телендә алып барылса да, нәниләр русча сөйләшә. «Балалар бакчалары өчен дә туган телдә шундый кызыклы китаплар эшләп бирегез әле!» – дип сорый тәрбиячеләр.



**Л.Г.:** Төрле чаралар, семинарларда катнашу өчен, безгә еш кына республикабыз шәһәрләренә, районнарына барырга туры килә. Анда укытучылар, укучылар белән очрашу, аралашу дәреслек язганда да безгә файдалы булды. Ачык дәресләр, мастер-класслар вакытында балаларның туган телебезне ни дәрәҗәдә белүләрен үз күзләребез белән күрдек. Апробация башлангач, укытучыларның дәресләренә йөрдек, балаларны да күзәттек. Шуңа күрә дәреслекләрне бүгенге көн укучысын күздә тотып эшләргә тырышабыз.

**«ИДЕЛ»: Элегрәк татар теленә өйрәтү дәреслекләренең кайберләре җитди тәнкыйтькә дучар була иде дип хәтерлим. Менә хәзер милли мәгариф бүлеге үз эшендә элекке китапларга, программаларга, методикаларга карата булган тәнкыйтьне искә аламы?**

**К.М.:** Телгә өйрәтү, аның методикасын һәм дәреслекләрен эшләү беркайда һәм беркайчан да кыска гына вакыт эчендә тормышка ашырылмаган. Инглиз теле булсынмы ул, русмы – бу нәрсәләр гасырлар дәвамында чарланган, җайга салынган. Әйтик, рус теленең бөтен мөмкинлекләре, механизмнары дәүләт тарафыннан куелган. Ә безнеке – бөтенләй икенче. Дәреслекләребезне рус, инглиз теле дәреслекләре белән чагыштыралар, безнең укытучыларның әзерлегенә ризасызлык белдерәләр. Монда нинди чагыштыру булырга мөмкин? Мәсьәлә алай гына хәл ителә торган түгел. Әйе, вакытында дәреслекләрне дә, укытучылар әзерләүне дә камилләштерә ала идек. Чөнки, минем аңлавымча, туксанынчы еллар уртасыннан әлеге мәсьәләләргә карата акыллы фикерләр дә әйтелде. Камилләштерә торган юлдан да китеп була иде.

Бүген институтның милли мәгариф бүлеге милли телдә дәреслекләр язу белән шөгыльләнә икән – алар булган тәҗрибәне өйрәнә, бихисап материаллар кулланып, яңаны булдыра.

**«ИДЕЛ»: Кайбер дәреслек авторларын, «Мәктәптә укытмаган кеше нинди дәреслек яза алсын?!» дип тәнкыйтьләгәннәрен ишеткән бар...**

**М.Ш.:** Безнең бүлек хезмәткәрләре турында алай әйтергә берәү дә җөрьәт итмәс. Мәктәптә эшләү, студентларны укыту юнәлешендә олы тәҗрибәбез бар. Методика фәнен өйрәткән укытучыларның урыны мәктәптә инде. Студентлар белән практика вакытында да гел шунда кайный идек.

**К.М.:** Яңа бүлек хезмәткәрләре – һәрберсе үз хезмәтенең остасы. Алар белән эшләве рәхәт. Һәрбер мәсьәләгә концептуаль карашлары бар. Безнең милли мәгариф бүлеге эшен Мәгариф һәм фән министрлыгы хуплый, ләкин эшебез бит министрлык хупласын өчен генә түгел. Башкалар да хуплый, димәк, дөрес юнәлештә барабыз.

**«ИДЕЛ»: Соңгы елларда, татар телен башлангыч мәктәптә укытсаң, шул җитә, дигән фикерләр дә яңгырый. Галимнәр фикере ничек икән?**

**К.М.:** Соңгы вакытта сөйләшү, яшәү тарая. Авыл тормышы белән бәйле сүзләрне, гыйбарәләрне бик оста итеп кушып сөйләшеп булмый – күп вакытта аларны искә төшерә алмый аптырыйсың, чөнки куллану сирәгәя. Әйтик, урманга барсаң, гөл-чәчәкләрне дә, агачларны да исемнәре белән атап бетереп булмый.

Телебезнең нинди зур катламы онытыла, әкренләп югала! Башлангыч мәктәп белән чикләнеп, ана телен өйрәнүне дүрт сыйныф укыганнан соң туктатасың икән, анда үзебезнең тел белән бәйле рәвештә атамалары да, гомумән,

дөньяга караш та, дөньяны аңлау да – барысы да тукталып калачак. Безнең буын әле ярый, онытылган сүзләрне искә төшереп, куллана ала. Ә мәктәптә татар телен укымаган кеше ничек куллана алсын?!

**«ИДЕЛ»: Иң шәп дәреслектән укытыр өчен дә беренче нәүбәттә укытучылар кирәк...**

**М.Ш.:** Яңа дәреслекләрнең концепциясен татар теле укытучылары белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында узган семинарларда җентекләп тикшердек. Укытучылар үзләрен борчыган сорауларга җавап табып, кайсы материалны ничек өйрәтергә, нәрсәгә аеруча игътибар итәргә, күпме күләмдә алырга икәнлеген билгеләделәр, яңа дәреслекләрнең концепциясе, программаларның эчтәлеге белән кызыксындылар.

Соңгы елларда институтта уннан артык методик семинар уздырылды. Бүлек оештырылганнан башлап, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе башлыгы Лилия Марс кызы Әхмәтҗанова җитәкчелегендә республиканың барлык районнарында диярлек булып, татар теле укытучылары һәм методистлары, мәктәп директорлары белән очрашып, яңа төр дәреслекләргә презентацияләр үткәрдек.

**К.М.:** Укытучылар әзерләү дәреслекләр язу белән параллель рәвештә барырга тиеш, алар бер-берсенә бәйле. Авылдан килеп укырга кергәннәрнең хәзерге заманда шәһәр балаларына татар телен укытырга әзерлеге җитәме? Мин дәүләт имтиханында, диплом яклауда катнашканда алган тәэсиремне генә уртаклашам. Менә хәзер өр-яңа полилингваль мәктәпләр төзиләр – анда эшләргә кемнәр килер? Моның тагын бер ягы бар: кеше үз юнәлешендә күпме алга киткән, белемлерәк – ул шуның кадәр үк милли мәсьәләдән ераклаша, чөнки ике юнәлешне дә кушып яшәүне авырсына. Шуңа күрә мәктәпләргә кем баруы борчый да инде, анда эшләр өчен алдынгы карашлы кешеләр кирәк.

**М.Ш.:** Мин 1992 елдан Казан дәүләт университетында (аннары – КФУда) татар телен укыту методикасын да өйрәттем. Әлбәттә, ул чорда рус мәктәбен һәм татар мәктәбен тәмамлаган балалар арасында аерма бар иде. Ким Мөгаллимович телгә алган, авылдан килгән студентлар, бәлки, барысы да рус һәм инглиз телен белеп килмәгәндер дә. Ләкин араларында шундый йолдызлар үсә иде! Башкалары да аларга карап тырыша, төрле конкурсларда катнаша. Дүртенче-бишенче курска җиткәндә бөтенләй диярлек тигезләшеп бетәләр иде. Дүртенче курс студентлары белән – өч ай, бишенче курслар белән дүртәр ай практика уздык. Студентлар такта янында басарга, тактага ничек язарга, укучылар белән ничек эшләргә, дәрес планнары, дәрес эшкәртмәләре язарга, дәрестән тыш чаралар үткәрергә – барысына да өйрәнеп китәләр иде. Мәктәп укытучыларының студентларга мөнәсәбәте бик яхшы булды, кулдан килгәнчә ярдәм иттеләр, аларга, чын мәгънәсендә, үрнәк күрсәттеләр.

**Л.Г.:** Ул буын студентларыбыз инде күптән мәктәпләрдә укыта. Алар – татар теленнән яңа дәреслекләрне сынаганда безнең таянычыбыз.

**М.Ш.:** Яңа дәреслекләр эшләргә тотынганчы, без башта күренекле методистлардан Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев, Ризатдин Сәләхетдин улы Газизов, Мирза Исмәгыйль улы Мәхмүтов, Мирфатыйх Зәкиев, Флера Сафиуллина һ.б. хезмәтләрен өйрәндек.

Заман бездән баланың татар телендә үзенең сөйләмен төгәл оештырып, теләсә нинди әңгәмәдә катнаша алуын, үз фикерен иркен һәм дәлилләп бирә белүен, телебезне укытуның максат-бурычларын һәм




*I сыйныф өчен дәреслек, аудиодәреслек, эш дәфтәреннән торган комплект*

күтелгән нәтиҗәләрне тулы һәм ачык күзаллауны таләп итә. Дөньяда югалып калмый торган, төрле ситуациядән чыга белә торган балаларны ничек тәрбияләргә? Безнең дәреслекләр проблемалы укытуга корылган, аларда тормышта очрый торган ситуацияләр бар. Балалар үзләрен теге яки бу хәлләргә куеп карый, алардан чыгу юлларын татар телендә фикер йөртеп эзли.

**Л.Г.:** Әйе, дәреслек тормышчан булырга тиеш. Балалар үзләренә төрле яклап мәгълүмат алсын, уйларга, аралашырга да өйрәнсен. Сүзләр, кагыйдәләр ятлатып кына телне өйрәнү алымыннан без киттек. Балалар татар теле дәресләрендә шушы дәреслек буенча уйнасын, кроссвордлар чишсен, әкиятләр сөйләсен!

Замана балалары инде моның белән генә дә канәгатьләнми. Аларга фантастика, фэнтезины, мультимедиа ысулларын тәкъдим итәбез. Аудиодәреслектән татарча текстларны һәм биремнәрне тыңларга була. Аларны Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары укый.

Дәреслеккә агачлар, кошлар, җәнлекләр, табигать турында бик күп яңа, кызыклы фактлар керттек. Дөресен әйтим, болар арасында хәтта өлкәннәр өчен дә кызыклы мәгълүмат җитәрлек.

**М.Ш.:** 1991 елдан бирле дәреслекләр өч юнәлештә һәм аерым-аерым эшләнелә иде: татар мәктәпләре, рус мәктәпләрендәге татар төркемнәре һәм рус телендә сөйләшүче балалар өчен. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, ике юнәлешне бергә кушып, яңа дәреслекләр әзерләп карарга тәкъдим итте. Дәреслектә ике юнәлеш бергә кушылды: база өлешен өйрәнүчеләр һәм туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр. «База өлешен өйрәнүчеләр» дигәндә рус мәктәпләренең татар төркемнәренә телне өйрәтүне, ә «тирәнтен өйрәнүчеләр» дип татар мәктәпләрендә, гимназияләрдә укучы балаларны күзалларга кирәк. Татар телендә иркен сөйләшүче балалар өчен «Куян күчтәнәче» – өстәмә биремнәр, күнегүләр тәкъдим ителә. Рус мәктәпләренең татар төркемнәре өчен кагыйдәләр, биремнәр гадиләштереп бирелде. Телгә өйрәтүдә күбрәк коммуникатив, социомәдәни, этномәдәни компетенцияләргә нигезләндек: татар дөньясы, сәнгате, тарихы, татар менталитеты, гаиләдә олыларны зурлау, исәнләшә белү, рәхмәт әйтү, кунак каршылау һ.б.

**Л.Г.:** Бик озак баш ваттык: ике төрле дәреслекне бер китап эчендә ничек берләштереп булыр икән? Һәм бу безгә нәрсә бирә? Бик катлаулы бурыч тора иде алдыбызда. Әле бит аның башта программасын эшләргә кирәк. Рус мәктәпләрендә дә күчле татар балалары бар. Андый сәләтле балаларга инде бөтәннәр белән беррәттән гади күнегүләр эшләп утыру кызык түгел. Укытучы аларга катлаулырак «Куян күчтәнәчен» биреп кызыксындыра ала.

Бүгенге көндә туган телне өйрәнүгә программада атнага ике сәгать кенә бирелсә дә, дәреслекләр өч сәгать исәбеннән эшләнде. Бердән, бу укытучыларга бирем, күнегүләрне сайлап алып эшләргә уңайлы булса, икенчедән, предметны укытуга мәктәп фондыннан өстәмә дәрес бирелү мөмкинлеге исәпкә алынды.

**«ИДЕЛ»: Элекке әдәбият дәреслекләренә кергән текстлар инде искергәндер. Классиклар яисә бүгенге заман әдипләреннән кемнәрнең әсәрләрен сайлап аласыз?**

**Г.М.:** Без әдәби уку дәреслекләренә, хрестоматияләренә кертү өчен байтак яңа әсәрләр сайлап алып әзерләдек. Бу шактый кыен эш булып чыкты, чөнки балалар укырлык кечкенә генә, шул ук вакытта эчтәлекле әсәрләр бик аз. Шигырьләр турында алай дип әйтеп булмый, ә менә проза әсәрләрен сайлау авыррак булды. Сәбәбе – алар бик авыр тел белән язылган. Аларны балалар өчен адаптацияләп бирергә туры килә. Шушындый проблема белән очраштык. Башлангыч сыйныфларда татарча текстлар җитмәү кыенлыгы аеруча сиздерә.

Әлегә беренче сыйныф өчен дәреслек язылды – контенты әзер, ул рәссамга тапшырылды. Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Бари Рәхмәт, Дәрҗия Аппакова, Шәүкәт Галиев кебек классик язучыларыбыз әсәрләре белән беррәттән, балалар өчен иҗат итүче хәзерге әдипләребезнең әсәрләрен дә бирдек. Китапханәләрдә эзләнеп утыру нәтиҗәсендә, укучыларга Роберт Миңнуллин, Хәкимҗан Халиков, Фәнис Яруллин, Резеда Вәлиева, Разил Вәлиев, Айгөл Әхмәтгалиева, Рафис Корбан, Рөстәм Мингалим, Ләбиб Лерон, Галимҗан Гыйльманов, Ленар Шәех һ.б. язучыларның матур гына әсәрләрен тәкъдим итәбез. Фоат Садриевнең балалар өчен атап язылган «Тургай» дигән әсәрен рәхәтләнеп кулланабыз. Укучылар өлкәнәйгән саен, әдәби текстлар сайлау кыенлыгы бетәргә тиеш, чөнки өлкәнрәк сыйныфлар укырлык әсәрләр күп.

**М.Ш.:** Әлеге мәсьәлә безгә дә – туган тел дәреслекләрен



*Дәреслекләр авторлары (сулдан уңга) Лилия Гыйниятуллина, Мөслимә Шәкурова, Гөлназ Мөхәрләмова, Дилария Абдуллина*

эшләүчеләргә дә кагыла. Рус мәктәпләренең татар төркемнәрендә укучы балаларның телне белү дәрәҗәсе төрлечә бит. Тексттан җөмләләрне кыскартырга, кайчагында бераз үзгәртергә дә, гадиләштерергә, сүзләрнең синонимнарын эзләргә туры килде. Рәссамнар арасында конкурс үткәрдек, әллә балалар өчен әдәби әсәрләр язучылар арасында да бәйге үткәрикме икән дип уйлаган чаклар күп булды.

Рәссамнар конкурсында байтак рәссам катнашты, тик заманча татар теле дәреслекләрен бизәрлекләре – Диләрә Нәүрузова һәм Андрей Шляпкин гына сайлап алынды. Гаять кызыклы проект булды бу. Андрей Борисовичтан кыстыбый рәсемен ясавын сораган идек – ул аны шундый дөрес, «шундый тәмле» итеп ясап бирде.

**Л.Г.:** Моңарчы булган дәреслекләрдән тагын бер принципиаль аерма бар: элек китап грамматик темаларга корылган иде, ә хәзер – лексик темага. Барлык материал дүрт темага берләштереп бирелә. Әлеге лексик темалар бердән алып унберенче сыйныфка кадәр кабатлана. Балаларның яшь үзенчәлекләрен, кызыксыну даирәләрен исәпкә алып, һәр сыйныфта алар вак темаларга бүленә.

**М.Ш.:** Эш дәфтәрләре турында әйтми кала алмыйм. Укучылар ул дәфтәрләрдә рәхәтләнеп язалар, тоташтыралар, рәсем ясыйлар. Матур язу үрнәкләрен бишенче сыйныфка кадәр бирәбез, чөнки укучыларның язуы пөхтә түгел. Элек ул укытучылар матур язуны таләп итәләр иде, хәзер никтер балаларның язуына игътибар бирелми. Электрон дәреслектә бик матур уеннар бар. Быел карантин вакытында балалар әти-әниләре белән бергә өйдә дәреслек буенча эшләгәннәр.

**Л.Г.:** Дәреслектә грамматик материал да башкачарак бирелде. Фонетика, лексика, морфология һәм синтаксисны өйрәнүгә һәр сыйныфта билгеле бер күләмдәге сәгать каралган. Кулланыштагы дәреслекләрдә бер сыйныфта тел гыйлеменең бер-ике өлкәсенә генә игътибар ителә иде. «Без бу теманы инде өйрәнгән идек!», «Әлеге тема ни өчен хәзер бирелгән? Элек башка сыйныфта өйрәнә идек» дип тә әйтергә мөмкин укытучылар. Әмма мондый бирелеш очраклы түгел. Ел саен билгеле бер тема кабатланып кына калмый, ныгытыла, яңа мәгълүмат өстәлә.

**М.Ш.:** Үзебезнең уку әсбабын яза башлаганчы, бик күп дәреслекләр белән таныштык: инглиз, алман, француз, казах, фин, рус. Безне барысы да кызыксындырды: темаларны урнаштыру, бизәлеш, биремнәр, таблицалар һ.б. Әмма без үзебезчә эшләдек, берәүне дә кабатламадык.

**БЕЗНЕҢ БЕЛЕШМӘ:**

Туган тел (татар теле) һәм әдәбиятын укыту проблемаларын өйрәнү максатында 2016 елда Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында аерым бүлек оештырыла. Өйрәнелә торган проблемалар даирәсе киңәйгәч, 2018 елда, бүлекнең исеме милли мәгариф бүлеге дип үзгәртелә. Әлеге бүлекнең эшчәнлеге «Милли мәгариф: үсешнең теоретик-методологик һәм гамәли аспектлары» фәнни юнәлеше кысаларында тормышка ашырыла. Бүлектә татар теле һәм татар әдәбиятын уку-укыту проблемалары һәръяклап, шул исәптән, туган телләрне өйрәтүдәге заманча үзгәрешләрне дә исәпкә алып, фәнни югарылыкта тикшерелә. Милли мәгариф бүлегенең төп эшчәнлеге – татар теле һәм татар әдәбиятын өйрәтүдә яңа уку-укыту программалары төзү, заман таләбенә туры килерлек дәреслекләр булдыру.